**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 апрель № 236

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2007/2008 – 2014/2015 уку елларында Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планын тормышка ашыру чаралары турында» 2008 ел, 15 декабрь, 887 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 12 март, 134 нче; 2011 ел, 13 май, 380 нче; 2012 ел, 29 февраль, 179 нчы; 2012 ел, 7 август, 671 нче; 2012 ел, 10 август, 678 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 829 нчы; 2013 ел, 12 сентябрь, 650 нче; 2014 ел, 7 июль, 458 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләүне оештыру буенча Татарстан төбәк комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан М.Р.Шаһиәхмәтовны, Ю.И.Абдрееваны, Р.Т.Борһановны, П.Н.Лохановны, Ә.М.Мәзһаровны, И.Р.Хәйруллинны, А.Р.Шәфигуллинны, Л.Г.Якуповны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасының икътисад министры, коллегия рәисе Артем Алексеевич Здуновны;

Татарстан Республикасының транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары Тимур Заһид улы Ажимовны;

Татарстан Республикасының финанс министры урынбасары Алла Леонидовна Анфимованы;

Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Әмир кызы Зарипованы;

Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Александрович Леоновны;

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Илгиз кызы Миңнуллинаны;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Мәкъзүм Хәлимулла улы Сәлаховны;

Андрей Иванович Поминов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 9 апрель, б-553 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 29 июль, б-1380 нче; 2013 ел, 16 август, б-1491 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) теркәлгән Татарстан Республикасының электрон товар-мәгълүмат системасы эшчәнлеген тикшерүдә тоту буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан М.Р.Шаһиәхмәтовны, Г.Ч.Әхмәдиеваны, Э.Н.Нигъмәтҗановaны, Ш.Х.Сөнгатовны, Л.М.Сәетованы, А.М.Фроловны чыгарырга;

Артем Алексеевич Здунов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының икътисад министры, эшче төркем рәисе»;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасының икътисад министры урынбасары, эшче төркем рәисе урынбасары Булат Зөфәр улы Хаҗиәхмәтовны;

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе урынбасары Инсаф Мөшәррәф улы Галиевне;

Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры урынбасары Айдар Марат улы Каюмовны;

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Николай Леонидович Титовны;

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Фәрит Мөдәррис улы Хәнифовны;

Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Алмаз Шәүкәт улы Хөсәеновны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\236.doc